| «Рассмотрено» | «Согласовано» | «Утверждено» |
| --- | --- | --- |
| Руководитель МО: | Заместитель директора по УР | Директор школы |
| ________ С.М.Галимова | ______ С.Г.Мифтахова | __________ Г.Г.Миннекаева |
| Протокол №1 от 29.08.2023 г. | 28.08.2023 г. | Приказ №173 от 31.08.2023 г. |


ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат: 00EDB99E1B89836E8727D189626974157F
Владелец: Миннекаева Гольшат Гаптравефовна
Действителен: с 10.11.2022 до 03.02.2024


**Рабочая программа**
Афзаловой Гульназ Жаудатовны,
учителя родного языка и литературы высшей квалификационной категории
МБОУ-Верхнекибякозинская средняя общеобразовательная школа
Тюлячинского муниципального района Республики Татарстан
по учебному курсу «Лексикология татарского языка», 10 класс

Принято на заседании педагогического совета
протокол № 2 от 28 августа 2023 г.

2023-2024 учебный год

## I . Планируемые результаты

**Предполагается, что, усвоив программу элективного курса, учащиеся будут иметь опыт:**

- нахождения изучаемого явления в контексте;
- выбора изучаемых явлений из словарей;
- подбора примеров по памяти;
- определения классификационной группы изучаемого явления;
- группировки изучаемых явлений по указанным основаниям;
- лексико-фразеологического разбора текста;
- определения изучаемого явления в тексте;
- составления контекстов с включением изученных явлений;
- выявления и определения изобразительно-выразительных средств языка в соответствии с идейным замыслом, авторской позицией;
- проведения дискуссии;
- выступления с докладами;
- организации речи в соответствии с видом и ситуацией общения, прогнозирования развития диалога.

## II. Содержание учебного предмета

**“Татар теленең лексикологиясе” электив курсның максаты һәм бурычлары.** Курсның төп максаты, бурычлары, актуальлеге турында. Библиографик чыганаклар белән танышу.

**Лексика һәм аның өйрәнү объекты. Лексикологиянең тармаклары.** Лексика һәм аның өйрәнү объекты, аның төп аспектлары. Лексика һәм аның өйрәнү объекты. Лексикологиянең тармаклары:ономасиология (ономастика, топонимика, антропонимика), семасиология, этимология, фразеология.

**Сүзнең грамматик һәм атау вазифасы.** Сүзнең грамматик һәм атау вазифасы, номинатив вазифа. Сүз һәм предмет, сүз һәм төшенчә, сүзнең лексик мәгнәсе.

**Сөйләм теленең асылы: югалтулар һәм табышлар; матур әдәбиятта табу һәм эвфемизмнарны күзәтү.** Матур әдәбиятта табу (полинезия) һәм эвфемизмнарны күзәтү.

**Семасиология һәм аның типлары.** Чынбарлыктагы әйбер яки күренешкә мөнәсәбәтле лексик мәгънә төркемчәләре (номинатив һәм сигнал, туры һәм күчерелмә, бер һәм күпмәгънәле, конкрет һәм абстракт мәгънәләр). Аңга яки фикерләүгә мөнәсәбәтле лексик мәгънә төркемчәләре. (терминологик һәм гомуми, образсыз һәм образлы, эмоциональ һәм эмцоиональ булмаган мәгънәләр)

**Лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга карап бүленеше**. (синонимик һәм антонимик, монолексик һәм омонимик, мотивлашкан һәм мотивлашмаган,нигез һәм ясалмага)

**Дөньяны танып-белүдә төшенчәле һәм образлы фикер йөртүнең әһәмияте**.

**Лексик мәгънәләрнең үсеше: метафора, метонимия, синекдоха.** Вазифа буенча күчеш. Катахреза. Сөйләм агышында, монологта, диалогта сүзнең бары бер генә мәгънә алуы.

**Синонимнар. Синонимнар оясы (рәте).** Синонимнарның барлыкка килү юллары: алынма сүзләр, җирле сөйләм, тарихи үзгәрешләр, табу, эвфемизмнарның төрләре, жаргон сүзләр, иске сүзләрне кайтару.

**Антонимнарның образлы сөйләмдәге роле**. Антитеза. Сөйләмдә сүзләрнең бәйләнешкә керүе- оксюморон барлыкка килү.

**Омонимнар, аларның төрләре**. (саф лексик, омографлар, омофоннар, омоформалар).

**Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составы.** Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составын кулланылыш активлыгы ягыннан актив һәм пассив сүзләр, кулланылыш сферасы буенча киң һәм тар кулланылыштагы сүзләр, килеп чыгышы ягыннан гомумтөрки һәм татар теленең үз сүзләре, алынмалар тәшкил итә.

**Фразеологик синонимнар**. Фразеологик синонимнарның тел һәм контекстуаль төрләре бар. Тел синонимнарының аермалы (дифференциаль) билгеләре берничә булырга мөмкин: үз

эчендә эчтәлекләре ягыннан (семантик синонимнар), нинди стильдә кулланылуы һәм эмоциональ-экспрессивлыгы ягыннан (стилистик синонимнар).

**Фразеологик антонимнар.** Фразеологик антонимнар, образлы сурәтләү чаралары буларак, матур әдәбиятта һәм сөйләү телендә әһәмиятле урын тоталар. Аларның сәнгатьлелеге, стилистик төсмерләре, тәэсир итүчәнлекләре, гади антонимнар белән чагыштырганда, күпкә көчлерәк, үтемлерәк һәм җанлырак.

**Фразеологик омонимнар.** Саф фразеологик омонимнар, шартлы фразеологик омонимнар, катнаш фразеологик омонимнар.

**Этимология тармагы турында гомуми мәгълүмат. Этимологик тикшеренү ысуллары**. Э т и м о л о г и я (грек. etymon – хакыйкать, чынлык, дөреслек һәм logos – өйрәнү) термины өч мәгънәдә кулланыла: 1) сүзнең килеп чыгышын өйрәнә торган фән; 2) сүзнең килеп чыгышын ачыклау максатыннан файдаланыла торган алымнар җыелмасы һәм әлеге эшчәнлекнең нәтиҗәсе; 3) сүзнең килеп чыгышы (Лингв. энцикл., 2000: 596). Этимон сүзе үзе генә хәзерге фәндә «сүзнең билгеле булган иң борынгы формасы» мәгънәсендә кулланыла. Этимологик анализ махсус ысулларга таянып алып барыла. Аларга түбәндәгеләр керә: эчке реконструкция, аналогия (индукция), күперчекләр табу һәм изоглоссалар табу.

**Сүз тамыры этимологиясе. Нигез һәм кушымчалар этимологиясе.** Сүз тамырының ясалышы – этимологиянең төп тикшерү предметларының берсе. Синхрон тел гыйлемендә сүз тамыры бүленми торган морфема буларак каралса, этимологиядә исә беренчел тамырларны аеру мәсьәләсе үзәккә куела. Тамыр ясалу юллары түбәндәгеләр: гаплология, конверсия һәм лексикалашу, чит телдән үзләштерү, дублетлашу һәм кабат таркалу. Татар телендәге таркатылмас нигезләр тарихи яктан түбәндәгечә классификацияләнәләр: 1) гомумтөрки нигезләр; 2) татар теленең үзендә генә булган нигезләр; 3) төрки булмаган теллләрдән алынма нигезләр.

**Татар теленең үз сүзләре һәм алынма сүзләр этимологиясе.** Һәрбер телнең сүзлек составында үз сүзләре һәм алынмалар барлыгын беләбез. Татар теленең сүзлек составында өч катлам аерыла: 1) төрки мирас, 2) тарихи алынмалар, 3) татар теленең үзендә барлыкка килгән сүзләр.

**Татар телендә алынма лексика.** Татар телендә фин-угор алынмалары. Татар телендә гарәп һәм фарсы алынмалары. Рус һәм Европа телләреннән кергән алынмалар.

**Гомумкулланылыш лексикасы**. Гомумкулланылыш (гомумхалык) лексикасы дип милли телнең нигезен тәшкил иткән, татар телендә сөйләшүчеләрнең барысына да аңлашыла торган, кулланылышында иҗтимагый һәм территориаль чикләр булмаган сүзләр.

**Җирле диалект лексикасы.** Урта диалект. Мишәр диалекты. Көнчыгыш диалект.

**Диалектизмнарның төрләре.** Фонетик диалектизмнар. Морфологик диалектизмнар. Семантик диалектизмнар. Фразеологик диа лектизмнар. Алынма диа лектизмнар. Синтаксик диалектизмнар.

**Татар телендә иҗтимагый диалект лексикасы.** Телнең иҗтимагый диалект лексикасы турында гомуми мәгълүмат. Иҗтимагый диалектизмнарның төрләре. Иҗтимагый диалект лексикасының функциональ-стилистик вазифасы.

**Татар теленең терминологиясе.** Татар теле терминологиясен өйрәнү тарихы. Татар теле терминологиясенә гомуми билгеләмә. Татар телендәге терминнарның чыганаклары. Терминнарның структур-ясалыш үзенчәлекләре. Терминологик һәм гомумкулланылыш лексикасының үзара мөнәсәбәте.

**Стильара лексика**. Стильара сүзләр сүз ясалыш ояларын һәм коннотатив, экспрессив төсмерләрне булдыруда, күчерелмә мәгънәләрне, терминологияне барлыкка китерүдә ясагыч-нигез вазифасын үтиләр.

**Китап теле лексикасы.** Китап теле лексикасына гомуми билгеләмә. Рәсми эш кәгазьләре лексикасы. Фәнни лексика. Иҗтимагый-публицистик лексика. Матур әдәбият теле лексикасы.

**Сөйләм теле лексикасы.** Сөйләм теле лексикасына гомуми билгеләмә. Сөйләм теле лексикасының төрләре. Гади сөйләм лексикасы. Экспрессив-стилистик лексиканың функциональ вазифасы.

**Татар теленең сүзлек составы: кулланылыш активлыгы.** Тел белемендә кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составын өйрәнү тарихы. Татар теленең актив һәм пассив лексик фондына гомуми билгеләмә.

**Татар телендә искергән сүзләр.** Татар телендә тарихи сүзләр һәм аларның төрләре. Архаизмнар һәм аларның төрләре.

**Татар телендә неологизмнар.** Неологизмнарның төрләре. Татар телендә неологизмнарның ясалыш юллары. Пассив лексиканың функциональ-стилистик вазифасы.

**Татар лексикографиясе фәненә кереш.** Лексикографиянең статусы һәм башка фәннәр белән бәйләнеше. Сүзлекләрнең хәзерге җәмгыятьтәге роле һәм урыны. Лексикография фәненең төп төшенчәләре. Татар теле сүзлекләренең типологиясе һәм структурасы. Сүзлек төзү этаплары һәм принциплары.

**Татар лексикографиясе тарихы.** Башлангыч чор сүзлекләре. XIX гасыр сүзлекләре. XX гасыр башы сүзлекләре. XX гасырның 20–40 нчы еллар сүзлекләре. XX гасырның 50–80 нче еллар сүзлекләре . XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы сүзлекләре.

**Татар сүзлекләренең төрләре.** Аңлатмалы сүзлекләр. Ортологик сүзлекләр. Диалектологик сүзлекләр. Этимологик сүзлекләр. Алынмалар сүзлекләре. Ономастик сүзлекләр. Фразеологик сүзлекләр. Терминологик сүзлекләр. Сүзлекләрнең башка төрләре.

**Йомгаклау дәресе.** Еллык материалны кабатлау.

## III. Календарно-тематическое планирование

| № п/п | Тема | Сәг. саны Кол-во часов | Дата | | Искәрмә примечание |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| 1. | “Татар теленең лексикологиясе” электив курсның максаты һәм бурычлары. | 1 | | | |
| 2. | Лексика һәм аның өйрәнү объекты. Лексикологиянең тармаклары. | 1 | | | |
| 3. | Сүзнең грамматик һәм атау вазифасы. | 1 | | | |
| 4. | Сөйләм теленең асылы: югалтулар һәм табышлар; матур әдәбиятта табу һәм эвфемизмнарны күзәтү. | 1 | | | |
| 5. | Семасиология һәм аның типлары. | 1 | | | |
| 6. | Лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга карап бүленеше. | 1 | | | |
| 7. | Дөньяны танып-белүдә образлы фикер йөртүнең әһәмияте. | 1 | | | |
| 8. | Лексик мәгънәләрнең үсеше: метафора, метонимия, синекдоха. | 1 | | | |
| 9. | Синонимнар. Синонимнар оясы (рәте). | 1 | | | |
| 10. | Антонимнарның образлы сөйләмдәге роле. | 1 | | | |
| 11. | Омонимнар, аларның төрләре. | 1 | | | |
| 12. | Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составы. | 1 | | | |
| 13. | Фразеологик синонимнар. | 1 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 14. | Фразеологик антонимнар. | 1 | | | |
| 15. | Фразеологик омонимнар. | 1 | | | |
| 16. | Этимология тармагы турында гомуми мәгълүмат. Этимологик тикшерену ысуллары. | 1 | | | |
| 17. | Сүз тамыры этимологиясе. Нигез һәм кушымчалар этимологиясе. | 1 | | | |
| 18. | Татар теленең үз сүзләре һәм алынма сүзләр этимологиясе. | 1 | | | |
| 19. | Татар телендә алынма лексика. | 1 | | | |
| 20. | Гомумкулланылыш лексикасы. | 1 | | | |
| 21. | Җирле диалект лексикасы. | 1 | | | |
| 22. | Диалектизмнарның төрләре. | 1 | | | |
| 23. | Татар телендә иҗтимагый диалект лексикасы. | 1 | | | |
| 24. | Татар теленең терминологиясе. | 1 | | | |
| 25. | Стильара лексика. | 1 | | | |
| 26. | Китап теле лексикасы. | 1 | | | |
| 27. | Сөйләм теле лексикасы. | 1 | | | |
| 28. | Татар теленең сүзлек составы: кулланылыш активлыгы. | 1 | | | |
| 29. | Татар телендә искергән сүзләр. | 1 | | | |
| 30. | Татар телендә неологизмнар. | 1 | | | |
| 31. | Татар лексикографиясе фәненә кереш. | 1 | | | |
| 32. | Татар лексикографиясе тарихы. | 1 | | | |
| 33. | Татар сүзлекләренең төрләре. | 1 | | | |
| 34. | Йомгаклау дәресе. | 1 | | | |